ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАГРЯЖСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАГРАЖ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**24.10.2025** **№ 24**

**«Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 21 нче мартында 5 нче номерлы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 21 нче мартында 5 нче номерлы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта 2.5.1:

а) 4 пунктчада «мөрәҗәгать итүче булмаган затның персональ мәгълүматларын эшкәртү кирәк» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче булмаган затның персональ белешмәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирү һәм аларны эшкәртү кирәк» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 4.1 өлеш өстәргә: «4.1. Мөрәҗәгать итүче булмаган затның персональ белешмәләре бирелгән очракта, федераль башкарма хакимият органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары, шулай ук дәүләт

һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү өчен ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасы ярдәмендә мондый затның яисә мондый затның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә законлы вәкиленең күрсәтелгән максатларда ризалыгын алу таләп ителми.».

2. Әлеге карарны авыл җирлекләре торак пунктларындагы мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **П.Н. Минеев**